ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

"10" ноябрь 2025 ел. Иске Абдул авылы № 13

**"Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегенең Иске Абдул авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Абдул авыл җирлеге Советының 20.11.2019 ел, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «Нигезләмәне раслау хакында»10/1 номерлы

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегенең Иске Абдул авылында 2025 елның 22 ноябрендә 16.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Иске Абдул авыл җирлегенең Иске Абдул авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Иске Абдул авыл җирлегенең Иске Абдул авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Абдул авылы юлларын ремонтлау вак таш сатып алу);
- урамнарны яктырту җайланмасы (Электроматериаллар сатып алу, Иске Абдул авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

"ӘЙЕ" "ЮК"

2.1 Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Иске Абдул авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Иске Абдул авылы, Үзәк урамы, 16 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Иске Абдул җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина